РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№_131**

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы финанслары белән идарә итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында Муниципаль программасы

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең 2017 елның 20 декабрендә кабул ителгән 818 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы муниципаль финанслары белән идарә итү» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
10.02.2020 елның 131 номерлы карарына кушымта

# «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы муниципаль финанслары белән идарә итү» Муниципаль программасы

## 1. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы муниципаль финанслары белән идарә итү» |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2018 – 2020 еллар |
| Программаны эшләүче программаны | Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы |
| Программаны башкаручылар | Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет), Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба – ФБП) |
| Программаның максаты (максатлары) | Кукмара муниципаль районы бюджет системасының озак сроклы балансльлыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү<br>Муниципаль финанслар белән идарә итү сыйфатын күтәрү |
| Программаның бурычлары | 1) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессын оештыруны һәм гамәлгә ашыруны камилләштерү;<br>2) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру;<br>3) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты акчаларын куллануны һәм бюджет законнары үтәлешен финанс тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру, финанс контроле методларын камилләштерү. |

| | |
|---|---|
| Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме | Бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме<br>2018 ел – 21352,1 мең сум,<br>2019 ел – 20800,9 мең сум,<br>2020 ел – 21192,2 мең сум<br>- муниципаль район бюджеты:<br>2018 ел – 21352,1 мең сум,<br>2019 ел – 20800,9 мең сум,<br>2020 ел – 21192,2 мең сум |

## 2. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсендәге агымдагы вәзгыяткә анализ

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы муниципаль финанслары белән идарә итү» муниципаль программасы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән.

Башкарма комитетның бюджет, салымнар, финанс һәм исәп өлкәсендә ФБП муниципаль районның бердәм бюджет, финанс һәм салым сәясәтен эшләү һәм әлеге өлкәләрдә норматив-хокукый җайга салу функцияләре башкара торган вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итә.

Кукмара муниципаль районы социаль-икътисади үсешенең стратегик максатларына ирешүнең төп шартларыннан берсе – муниципаль район бюджетының кирәкле керем дәрәҗәсен тәэмин итүгә, районның чыгым йөкләмәләрен тулысынча һәм үз вакытында үтәү максатыннан өстәмә финанс ресурсларын мобилизацияләүгә юнәлдерелгән финанс, бюджет, салым һәм бурыч сәясәтен грамоталы үткәрү.

Муниципаль берәмлектә бюджет-финанс системасы өзлексез үзгәреп торучы федераль законнар шартларында үсә, бу системаның тотрыксызлыгына һәм уртача сроклы һәм озак сроклы финанс фаразларын дөрес гамәлгә ашыру мөмкин булмавына китерә. Ел дәвамында ФБП агымдагы елга район бюджеты күрсәткечләрен берничә тапкыр яңадан карарга һәм төзәтмәләр кертергә мәҗбүр булды.

1 нче таблица Муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсендә агымдагы вәзгыятьне характерлаучы күрсәткечләр

| N | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 бәя |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Хисап чоры ахырына муниципаль эчке бурыч күләме | мең сум | 569,6 | 427,2 | 284,8 | 142,4 | 0 |
| 2 | Муниципаль район бюджеты керемнәренә муниципаль бурычның гомуми күләменең мөнәсәбәте (башка дәрәҗәләрдәге бюджетлардан кире кайтарылмый торган түләүләрне исәпкә алмыйча) | % | 0,2 | 0,1 | 0,09 | 0,04 | 0 |
| 3 | Кире кайтарылмый торган керемнәрнең күләмен исәпкә алмыйча, муниципаль район бюджеты керемнәре күләменә муниципаль район бюджеты дефицитының мөнәсәбәте | % | 17,2 | 12,8 | 3,05 | - | 8,1 |
| 4 | Районның рәсми сайтында мәгълүмат бирү тулылыгы | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

Хәзерге вакытта муниципаль район бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру актуальләшә бара.

Бу түбәндәгеләр белән бәйле:

- Чираттагы финанс елына һәм план чорына (өч еллык бюджетка) муниципаль районның планлаштыру горизонтын киңәйтәчәк, бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыруның сыгылмалылыгын арттырачак һәм өч еллык перспективага алдан уйланылган финанс карарларын кабул итүгә ярдәм итәчәк бюджетын формалаштыруга күчү,
- муниципаль район бюджетын, озак сроклы максатчан программаларны, муниципаль район бюджеты чыгымнарын эшчәнлек нәтиҗәләренең сан ягыннан күрсәткечләре белән бәйләгән, чыгымнар турында, шул исәптән аларны гамәлгә ашыруның пландагы нәтиҗәләреннән чыгып, карарлар кабул итәргә мөмкинлек биргән муниципаль биремнәрне төзү һәм үтәүне практикага кертү. 2015 елдан муниципаль район бюджетын Кукмара муниципаль районның муниципаль программалары нигезендә төзүгә күчтек;
- элек кабул ителгән (билгеләнгән) йөкләмәләрнең тулы күләмдә үтәлешен тәэмин итә торган гамәлдәге һәм кабул ителә торган йөкләмәләрне бүлү нигезендә муниципаль район бюджетын төзү. Кабул ителә торган йөкләмәләрне конкурс нигезендә бүлүнең иң актуаль һәм нәтиҗәле

юнәлешләргә ресурслар бүлеп бирүне тәэмин итә торган механизмы кертелде;

- Муниципаль район бюджетының озак сроклы балансслылыгын тәэмин итү өчен бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру потенциалы бетмәде, Кукмара районының муниципаль финанслар секторындагы киеренкелекне булдырмау максатыннан, бу юнәлештә чараларны гамәлгә ашыру дәвам итәчәк.

### 3. Муниципаль программаны тормышка ашыруның максаты (максатлары) һәм көтелгән нәтиҗәләре

Муниципаль программаны тормышка ашыруның максатыл – Кукмара муниципаль районының бюджет системасының озак сроклы балансслылыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү, муниципаль финанслар белән идарә итүнең сыйфатын күтәрү.

2018 – 2020 елларда Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- муниципаль район бюджеты йөкләмәләренең үз вакытында һәм тулы үтәлешен, хисап елы азагына муниципаль бурыч булмауны, кредиторлык, шул исәптән кичектерелгән бурычлар булмауны тәэмин итәргә;

- муниципаль район бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген алга таба үстерүне тәэмин итәргә;

- Кукмара муниципаль районында бюджет процессы белән нәтиҗәле һәм сыйфатлы идарә итәргә.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләрен (шул исәптән гамәлгә ашыру еллары буенча) характерлаучы максатчан күрсәткечләр 2 нче таблицада күрсәтелгән. Максатчан күрсәткечләрнең хисап күрсәткечләре икътисадый вәзгыятьнең фаразланмаган үзгәрүе, дәүләт хакимияте дәрәҗәләре арасында чыгым вәкаләтләрен яңадан бүлү очрагында, шулай ук муниципаль район бюджеты керемнәрен һәм чыгымнарын объектив үзгәртүгә китерә торган башка очракларда пландагы күрсәткечләрдән үзгә булырга мөмкин.

2 нче таблица Программаны гамәлгә ашыруның максатчан индикаторлары (күрсәткечләре) турында белешмәләр.

| N т/б | Максатчан индикатор (күрсәткеч) атамасы | Үлчәү берәмлеге | 2016 факт | 2017 Бәя | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль район бюджеты керемнәренә муниципаль бурыч күләменең (за вычетом бюджетных кредитов) мөнәсәбәте (кире кайтарылмый торган кертемнәр күләмен исәпкә алмыйча) | % | 0,04 | 0 | - | - | - |
| 2 | Кире кайтарылмый торган керемнәрнең күләмен исәпкә алмыйча, муниципаль район бюджеты керемнәре күләменә муниципаль район бюджеты дефицитының мөнәсәбәте | % | 0 | 8,1 | - | - | - |
| 3 | Югарыдагы бухгалтерлык һәм бюджет хисаплылыгы органнарына вакытсыз яисә сыйфатсыз бухгалтерлык яки бюджет хисабы тапшыру очраклары саны | тапкыр | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

1 нче номерлы максатчан күрсәткеч буенча хисап күрсәткечләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә Кукмара муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы бюджет хисаплылыгы күрсәткечләре нигезендә билгеләнә.

2 нче номерлы максатчан күрсәткеч буенча хисап күрсәткечләре Кукмара муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы бюджет хисаплылыгы күрсәткечләре нигезендә, Кукмара муниципаль районы

бюджеты дефицитының Кукмара муниципаль районы бюджетының түләүсез керемнәр күләме киметелгән (уменьшенному на объем безвозмездных поступлений) керем күләменә мөнәсәбәте буларак билгеләнә.

3 номерлы максатчан күрсәткечләр буенча хисап күрсәткечләре югарыдагы органнарның тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

## 4. Муниципаль Программаны ресурслар белән тәэмин итү

3 нче таблица Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

| № т/б | Программаның исеме /ресурслар белән тәэмин итү чыганагы | 2018, мең сум | 2019, мең сум | 2020, мең сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Программа, барлыгы: | 21352,1 | 20800,9 | 21192,2 |
| | шул исәптән | | | |
| | - муниципаль район бюджеты | 21352,1 | 20800,9 | 21192,2 |

## 5. Программа чаралары

Программаны тормышка ашыру түбәндәге төп чараларны башкаруны күздә тота:

1. Кукмара муниципаль районы бюджетын программа нигезендә формалаштыруга күчүне тәмамлау.

Муниципаль программалар бюджет чыгымнарын планлаштыру һәм үтәүнең бюджет ассигнованиеләрен Кукмара муниципаль районының социаль-икътисади үсеше максатларын, чыгымнарны гамәлгә ашыруның турыдан-туры һәм башка нәтиҗәләрен, шул исәптән куелган максатларга ирешүгә ярдәм итүче оештыру һәм регулятив чаралар белән бәйли торган комплекслы инструменты булып тора. Муниципаль программалар нигезендә бюджет төзүгә күчү хәзерге вакытта бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруның төп юнәлеше булып тора.

2013 елда районда Кукмара муниципаль районының муниципаль программаларын төзү һәм кабул итү процессы башланды, кирәкле норматив хокукый база кабул ителде, программалар төзү буенча бюджет акчалары администраторларына ярдәм оештырылды. 2018 – 2020 елларга муниципаль район бюджеты бюджет чыгымнарын «программалы» классификацияләүне исәпкә алып формалаштырылачак.

Программаның башкаручысы – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Кукмара районы Финанс-бюджет палатасы.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруга «чыгым түшәмнәре» («потолки расходов») нигезендә муниципаль район бюджеты чыгымнарын формалаштыруга күчү.

Чара Кукмара муниципаль районының һәр муниципаль программасы өчен чыгымнарның иң чик күләмнәре («чыгым түшәмнәре») билгеләнергә тиеш дип күздә тота. «Чыгым түшәмнәре» түбәндәгеләргә мөмкинлек бирә:

- бер яктан, финанс ресурсларының алдан фаразлануын арттыру, уртача вакытка планлаштыру буенча программалар администраторларының һәм башкаручыларының мөмкинлекләрен киңәйтү;

- икенче яктан, финанс дисциплинасы, муниципаль программаларны тормышка ашыру чыгымнарын бары тик «чыгымнар түшәмнәрев» кысаларында гына планлаштыруны тәэмин итү.

«Чыгымнар түшәмнәре» консерватив алымнардан чыгып билгеләнер дип көтелә, шул ук вакытта өстәмә ассигнованиеләрнең билгеле бер күләме кабул ителә торган йөкләмәләрне бүлү кысаларында программалар арасында чираттагы 3 елга үзәкләштерелгән рәвештә бүленәчәк.

«Чыгымнар түшәмнәре» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бер үк вакытта барлык муниципаль программалар өчен расланырга һәм Кукмара муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен җитәрлек булырга тиеш.

Программа чарасын ФБП башкара.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

3. Кукмара муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен үтәкүренмәле беркетүне тәэмин итү өлешендә норматив хокукый базаны камилләштерү.

Чара Кукмара муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен билгеләүче норматив хокукый актларына эзлекле төзәтмәләр кертү процессын оештыруны, яңа норматив хокукый актлар кабул итүне күздә тота (кирәк булганда).

Чараның үтәлеше ФБП (җаваплы башкаручы) тарафыннан бюджет акчаларын баш бүлүчеләр белән үзара бәйләнештә башкарыла, алар үз карамагындагы өлкәләргә чыгым йөкләмәләрен беркетү буенча хокукый актлар проектларын әзерләүне һәм килештерүне гамәлгә ашырырга тиеш.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

4. Бюджет учреждениеләре тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (эшләр башкару) финанс механизмнарын камилләштерү.

Чараны үтәү муниципаль учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудыручы чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота. Барыннан да элек, сүз Россия Федерациясе дәрәҗәсендә эшләү һәм кабул итү

планлаштырыла торган дәүләт хезмәтләренең бердәм регистры нигезендә муниципаль биремнәрне формалаштыруга күчү турында бара, Россия Федерациясе дәрәҗәсендә эшләү һәм кабул итү планлаштырыла. Күчүне тормышка ашыру түбәндәгеләрне таләп итә:

- Кукмара муниципаль районының муниципаль хезмәтләр исемнәрен, аларның эчтәлеген, һәм сыйфат стандартларын төгәлләштерү;

- муниципаль хезмәтләр күрсәтү күләме һәм сыйфаты характерлый торган күрсәткечләр исемлеген эшләп бетерү;

- муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнар нормативларын билгеләү тәртибен үзгәртү;

- Кукмара муниципаль районының муниципаль программаларына һәм муниципаль учреждениеләр өчен муниципаль биремнәргә төзәтмәләр кертү.

План чорында бюджет учреждениеләренә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль биремнәрне финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелгән субсидияләрдән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә торган инструментларны гамәлгә кертергә кирәк булачак. Әлеге инструментлар учреждениеләргә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тарафыннан квартал саен муниципаль биремнәрне үтәүнең фактик тайпылышлары турында мәгълүматны вакытында алырга, һәм, кирәк булган очракта, муниципаль йөкләмәне үтәмәгән өчен, учреждение җитәкчесенә тиешле чаралар күрергә, яисә муниципаль йөкләмә күрсәткечләрен үзгәртергә һәм кабул итәргә мөмкинлек бирә торган мониторинг уздыру юлы белән муниципаль биремнәр үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру эшен оештыруны күз алдында тота.

Мондый инструментлар булу бюджет учреждениеләренең финанс җаваплылыгының нигезе булып тора, аннан башка муниципаль биремнәрне үтәүгә чыгымнар нәтиҗәле була алмый.

Чараны тормышка ашыру ФБП тарафыннан муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыручы бюджет акчаларын баш бүлүчеләр белән үзара бәйләнештә башкарыла.

Чараны үтәү вакыты – 2018 – 2020 еллар (федераль дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләренең бердәм регистрын кабул итү вакыты белән билгеләнә).

5. Муниципаль район бюджетын төзү һәм үтәү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә «Электрон бюджет» системасының аерым элементларын кертү.

Чараны үтәү муниципаль финанслар белән идарә итү функцияләрен һәм процессларын алга таба автоматлаштыруга, кабатлаучы операцияләрне булдырмауга юнәлдерелгән.

Программа чарасын ФБП башкара.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

6. бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелегенә финанс контроленә күчү.

Чараны үтәү Россия Федерациясе дәрәҗәсендә дәүләт (муниципаль) финанс контролен тормышка ашыру кысаларында планлаштырыла. Әлеге реформаның төп элементлары: бюджет законнарын бозган өчен җаваплылык һәм мәҗбүр итү чараларын билгеләү; эчке финанс контролен үстерү; финанс контроленең бердәм стандартларын кертү; тышкы финанс контроленә нәтиҗәлелекне бәяләүгә яңадан юнәлеш бирү.

Соңгы элемент бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итүдә мөһим роль уйный, чөнки әлеге максатлар өчен бюджет акчаларын максатчан куллануны (хәзерге вакытта артып китүче) контрольдә тоту потенциалы, нигездә, беткән.

Турыдан-туры нәтиҗәләргә ирешүне контрольдә тотуга юнәлдерелгән финанс тикшерүенең яңа формаларын кертү һәм карап тоту процессы күп очракта Россия Финанс министрлыгының норматив һәм методик инициативалары белән билгеләнәчәк.

Программа чарасын ФБП башкара.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

7. «Гражданнар өчен бюджет» еллык басмасын гамәлгә кертү.

«Гражданнар өчен бюджет» дигәндә, гражданнарга объектив, гади һәм аңлаешлы формада бюджет һәм аның үтәлеше турында актуаль мәгълүмат бирү максатларында финанс органы тарафыннан бастырып чыгарыла торган аналитик документ аңлашыла.

«Гражданнар өчен бюджетлар»ны бастырып чыгару муниципаль финансларның үтәкүренмәлелеген һәм ачыклыгын күтәрүгә, хисаплылыкны һәм җәмәгать контролен көчәйтүгә юнәлдерелгән чара буларак планлаштырыла.

«Гражданнар өчен бюджетлар»ны эшләү һәм бастырып чыгару Россия Финанс министрлыгының методик рекомендацияләре нигезендә ел саен башкарыла.

Программа чарасын ФБП башкара.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

8. Икътисадый хәлнең көтелмәгән начараюы очрагына муниципаль район бюджеты чыгымнарын киметү, шулай ук муниципаль район бюджетын киеренке параметрларда (кирәк булганда) кабул итү чараларын эшләү.

Әлеге чаралар бюджетның нинди чыгымнары, беренче чиратта, нинди күләмдә кыскартылырга мөмкин булуын билгеләргә тиеш.

Бюджет чыгымнарын киметү муниципаль биремнәрне норматив финанслауның кимүенә кагылмавы бик мөһим.

Программа чарасын ФБП башкара.

Чараны үтәү срогы – 2018 – 2020 еллар.

Программа чараларын үтәү ФБПның агымдагы эшчәнлеген финанслау кысаларында гамәлгә ашырыла.